**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы комиссия составына үзгәрешләр кертү турында**

Кайбер затларның башка эшкә күчүе белән бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге турында» 2004 елның 31 декабрендәге ПУ-824 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2005 елның 7 декабрендәге ПУ-479 номерлы, 2009 елның 29 гыйнварындагы ПУ-35 номерлы, 2011 елның 7 сентябрендәге ПУ-549 номерлы, 2013 елның 7 мартындагы ПУ-208 номерлы, 2014 елның 15 мартындагы ПУ-275 номерлы, 2015 елның 2 мартындагы ПУ-196 номерлы, 2016 елның 11 мартындагы ПУ-236 номерлы, 2018 елның 21 апрелендәге ПУ-329 номерлы һәм 2019 елның 8 февралендәге ПУ-89 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы комиссия (алга таба – Комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комиссия составыннан Р.И. Вәлиевны, З.Ф. Гыймаевны, Г.Р. Нигъмәтуллинаны, Р.А. Ратникованы, А.А. Фоминны чыгарырга;

б) Комиссия составына кертергә:

Әхмәтов Марат Готыф улын – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасарын (килешү буенча);

Вәлиева Зилә Рәхимҗан кызын – Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисен (килешү буенча);

Зарипов Айрат Ринат улын – Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисен (килешү буенча);

Низамова Ләйсән Габделхан кызын – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Мәдәният һәм Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү идарәсе башлыгын;

Шиабиев Альберт Хазинур улын – «Татарстан Республикасы Рәссамнар берлеге» төбәк иҗтимагый иҗат оешмасы рәисен (килешү буенча);

в) Комиссия әгъзасы В.Н. Кудряшевның вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Россия Архитекторлар берлеге» гомумроссия иҗтимагый һөнәри иҗат оешмасының «Татарстан Республикасы Архитекторлар берлеге» төбәк бүлекчәсе идарәсе рәисе (килешү буенча)».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2020 ел, 06 март
№ ПУ-158